КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 7 сентябрь г.Казань № 803

18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие турында

18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтүне көчәйтү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына Татарстан Республикасында халыкның җан башына исәпләгәндә билгеләнгән яшәү минимумы күләме белән гаиләнең җан башына уртача кереме арасындагы аермага тигез булган айлык пособие билгеләргә.

2. Бу карарга теркәлгән 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие бирү тәртибен расларга.

3. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие бирү тәртибен куллану буенча аңлатмалар Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла;

18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие бирү турындагы мәгълүмат «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла.

4. Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие бирү өчен кирәкле гамәли программа продуктын эшләүне тәэмин итәргә.

5. Бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 7 сентябрь, 803 нче
карары белән расланды

18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган
гаилә әгъзаларына айлык пособие бирү
тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Бу Тәртип 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие (алга таба – айлык пособие) бирү кагыйдәләрен һәм шартларын билгели.

2. Айлык пособие 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзасына (алга таба – алучы) Татарстан Республикасында халыкның җан башына исәпләгәндә билгеләнгән яшәү минимумы күләме белән гаиләнең җан башына уртача кереме арасындагы аермага тигез булган күләмдә билгеләнә һәм түләнә.

Айлык пособие Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына, чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга билгеләнә.

3. Айлык пособие түбәндәгеләргә билгеләнми:

тулысынча дәүләт тарафыннан тәэмин ителүдәге затларга (белем алуга бәйле булган, тулысынча дәүләт тарафыннан тәэмин ителүдәге затлардан тыш);

ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән яисә ата-ана хокуклары суд карары буенча чикләнгән ата-анага;

алиментлар түләү турындагы килешү буенча айлык пособие алучыга тулы керем бирергә йөкләмә алган яки суд карары буенча айлык пособие алучыга алиментлар түләттерелә торган ата-анага;

опекада (попечительлектә) булган балага;

никахлашуга яки аның эмансипациясенә бәйле рәвештә, тулысынча эшкә сәләтле булган 18 яшькә кадәрге балага;

иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтүче затларга; сак астына алу рәвешендә чик кую чарасы кулланылган затларга; тикшерү органнары яки суд карары нигезендә суд-медицина экспертизасы үтүгә бәйле рәвештә, суд карары буенча мәҗбүри дәвалануда булган затларга, шулай ук эчке эшләр органнары, суд приставлары-үтәтүчеләре тарафыннан эзләнә торган затларга;

чакыру буенча сержантлар, старшиналар, солдат яки матрослар буларак хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләргә, шулай ук хәрби һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче хәрби мәгариф оешмаларында укучы һәм хәрби хезмәт үтү турында контракт төземәгән хәрби хезмәткәрләргә.

4. Айлык пособие бирү максатларында 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган гаиләнең җан башына уртача кереме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибен раслау һәм «Татарстан Республикасында

халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 10 сентябрь, 625 нче карары белән расланган тәртиптә исәпләп чыгарыла.

## II. Айлык пособие билгеләү һәм түләү тәртибе

5. Айлык пособие билгеләү өчен алучы, алучының законлы вәкиле яки Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә ул вәкаләт биргән зат (алга таба – гариза бирүчеләр) түбәндәге документларны «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең яшәү урыны буенча бүлегенә (алга таба – Үзәк бүлеге) тапшыра:

банкта яки башка кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтеп, Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы раслаган форма буенча айлык пособие билгеләү турында гариза (алга таба – гариза);

алучының һәм аның гаилә әгъзаларының айлык пособие бирү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган керемнәрен раслый торган документлар;

бала (балалар) туу турында таныклык күчермәсе – Татарстан Республикасыннан читтә бала (балалар) тууны дәүләт теркәвенә алган очракта;

никахлашуны теркәүгә алу турында таныклык күчермәсе – Татарстан Республикасыннан читтә никахлашуны дәүләт теркәвенә алган очракта;

ышанычнамә – айлык пособие билгеләү өчен гариза аны алучы яки алучының законлы вәкиле тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән зат тарафыннан тапшырылган очракта;

алучының гаилә әгъзаларыннан яки аларның законлы вәкилләреннән түбәндәгене (түбәндәгеләрне) раслый торган документ (документлар) (ирекле рәвештә):

аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык булу;

гариза бирүченең шәхси мәгълүматларны органга яки оешмага тапшырганда алар исеменнән эш итәргә вәкаләте.

Документлар күчермәләре документның төп нөсхәсен биргән нотариус яки орган (учреждение) тарафыннан расланмаган очракта, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан раслана.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланган булырга тиеш.

6. Үзәк бүлеге ведомствоара соратулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, электрон рәвештә айлык пособие билгеләү турында карар кабул итү өчен кирәкле түбәндәге мәгълүматларны ала:

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүматлар – Татарстан

Республикасы территориясендә бала (балалар) тууны дәүләт теркәвенә алган очракта;

никахлашуны дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүматлар – Татарстан Республикасы территориясендә никахлашуны дәүләт теркәвенә алган очракта;

халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте органнары тарафыннан түләнә торган эшсезлек буенча пособие, стипендия, матди ярдәм алу һәм аларның күләме турында мәгълүматлар;

Россия Федерациясе Пенсия фонды органнары тарафыннан түләнә торган пенсия һәм башка социаль түләүләр алу һәм аларның күләмнәре турында мәгълүматлар;

эш бирүче (иминләштерүче) тарафыннан физик зат файдасына исәпләнгән, Россия Федерациясе Пенсия фонды органнары тарафыннан түләнә торган түләүләр һәм башка бүләкләүләр суммасы турында мәгълүматлар;

Социаль иминият фонды органнары тарафыннан түләнә торган социаль түләүләр турында мәгълүматлар;

ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү турында яки ата-ана хокукларын чикләү турында мәгълүматлар.

Гариза бирүче үз инициативасы белән Үзәк бүлегенә бу пунктта күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларны тапшырырга хокуклы.

7. Үзәк бүлеге барлык кирәкле документлар белән айлык пособие билгеләү турындагы гаризаны алган көннән 14 эш көне эчендә айлык пособие билгеләү турында йә аны билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм тиешле карарны гариза бирүчегә карар кабул ителгән көннән биш эш көне эчендә гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язма рәвештә, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, телефонга смс-хәбәр итеп) җиткерә.

8. Айлык пособие билгеләүдән баш тарту өчен булган мәгълүматлар һәм документлар җыелмасы нигезендә ачыкланган аны алуга хокук булмау нигез булып тора.

9. Айлык пособие барлык кирәкле документлар белән гариза тапшырган айдан билгеләнә һәм алты ай дәвамында түләнә.

10. Үзәк бүлегендә алучының айлык пособиегә хокукын раслый торган мәгълүматлар булган очракта, айлык пособие аңа яңа срокка алучыдан башка билгеләнә.

11. Алучының ризалыгы булганда һәм аның башка төр керемнәре булмаганда, айлык пособие билгеләү Россия Федерациясе Пенсия фондында булган, бу Тәртипнең 6 нчы пунктындагы алтынчы абзацында күрсәтелгән мәгълүматлар нигезендә айлык пособие билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән айга кадәр килгән 12 айның соңгы алты ае өчен гамәлгә ашырыла.

12. Айлык пособие бирү аны бирүне туктатуга китергән вакыйгалар килеп чыккан айдан соң килә торган айдан башлап туктатыла.

Алучыга айлык пособие бирүне туктату өчен түбәндәгеләр нигез була:

гаиләдә 18 яшькә кадәрге кимендә биш бала булу;

алучыны бу Тәртипнең 3 нче пунктында күрсәтелгән затлар категориясенә кертү өчен нигезләр барлыкка килү;

алучының үлеме;

алучының (алучыны) Татарстан Республикасыннан читтә даими яшәүгә күчүе (күчерү).

### III. Йомгаклау нигезләмәләре

13. Алучы бер ай эчендә Үзәк бүлегенә бу Тәртипнең 12 нче пунктындагы өченче, дүртенче, алтынчы абзацларында күрсәтелгән айлык пособие бирүне туктатуга китерә торган вакыйгалар башлану турында хәбәр итәргә тиеш.

14. Гариза бирүче тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге өчен, шулай ук алардагы документларның дөрес булуы өчен җавап бирә.

15. Гариза һәм айлык пособие алу өчен кирәкле документлар (мәгълүматлар) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Электрон документлар рәвешендә бирелә торган гаризалар һәм документлар (мәгълүматлар) Россия Федерациясе законнары нигезендә электрон имза белән имзалана һәм, электрон йөрткечләрне һәм (яки) гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен («Интернет» челтәрен кертеп) кулланып тапшырыла.

16. Үзәк бүлеге гариза бирүче тапшырган мәгълүматларның дөреслеген һәм документларның дөрес булуын раслау максаты белән, ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең төбәк системаларыннан файдаланып, дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм оешмаларга соратып алулар җибәрергә хокуклы.

17. Үзәк бүлеге тарафыннан айлык пособие алучыларның шәхси эшләрен формалаштыру һәм саклау гамәлгә ашырыла.

18. Айлык пособие банкта яки башка кредит оешмасында ачылган шәхси счетларга күчерү юлы белән алучыларга бирелә.

19. Дөрес булмаган мәгълүматлар белән документлар тапшыру, айлык пособие алу хокукына һәм аның күләменә тәэсир итә торган мәгълүматларны яшерү аркасында айлык пособиенең артык түләнгән суммасы алучы тарафыннан үз теләге белән, «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең казначылык счетына кертү юлы белән яки айлык пособиенең киләчәктә түләнәчәк суммасы исәбеннән каплана, ә алучы баш тарткан очракта Россия Федерациясе законнары нигезендә түләттерелә.

Айлык пособиенең алучыга артык түләнгән, шул исәптән аны исәпләгәндә Үзәк бүлеге тарафыннан җибәрелгән хата аркасында түләнгән суммасы айлык пособиенең киләчәктә түләнәчәк суммасы исәбеннән каплана.

20. Үзәк бүлегенең гаебе белән үз вакытында алынмаган айлык пособие үткән вакыт эчендә чикләнмәгән вакытта түләнә. Әлеге очракта айлык пособие суммасы бер тапкыр түләнә.

21. Айлык пособие бирү мәсьәләләре буенча бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.